Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы
Салман авыл җирлегенең Түбән Салман авылы торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

2019 елның 16 ноябре                                                    № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2019 елның 11 ноябрендәге 17 номерлы Әлки муниципаль районының «Салман җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 10 октябрендәге 16 номерлы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе»карары, 2019 елның 16 ноябрендәге 1 номерлы Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлегенең Түбән Салман авылында гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлеге составына керүче Түбән Салман авылында гражданнар җыенын үткәрелгән, ә җыен нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Салман авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күпбалалы гаиләләр, 80 яшьтән өлкәнрәк затлар һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

- Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлеге торак пунктларында урамнарны яктырту өчен кирәкле материал сатып алу, яктырту җиһазлары урнаштыру буенча электромантаж эшләре һәм урам утлары кулланган энергия өчен чыгымнарны түләүгә -100 сум.

- Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлеге торак пунктларында су башнялары территорияләрен коймалау, урамны су белән тәэмин итү системасын төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау белән бәйле чыгымнарга -100 сум.

- Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлеге торак пунктларында авыл эчендәге юлларга хезмәт күрсәтү һәм төзекләндерү белән бәйле чыгымнарга-200 сум.

- Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлеге территориясендә урнашкан зиратларга хезмәт күрсәтү һәм төзекләндерү белән бәйле чыгымнарга-100 сум.

-Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлеге торак пунктларында контейнерлар сатып алуга һәм каты көнкүреш калдыклары өчен контейнер мәйданчыкларын төзекләндерүгә бәйле чыгымнарга-100 сум мәсьәләләре буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Салман авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган,1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күпбалалы гаиләләр, 80 яшьтән өлкәнрәк затлар һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлеге торак пунктларында урамнарны яктырту өчен кирәкле материал сатып алу, яктырту җиһазлары урнаштыру буенча электромантаж эшләре һәм урам утларын куллану өчен чыгымнарны түләүгә -100 сум.

- Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлеге торак пунктларында су башнялары территорияләрен коймалау, урамны су белән тәэмин итү системасын төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау белән бәйле чыгымнарга -100 сум.

- Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлеге торак пунктларында авыл эчендәге юлларга хезмәт күрсәтү һәм төзекләндерү белән бәйле чыгымнарга-200 сум.

- Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлеге территориясендә урнашкан зиратларга хезмәт күрсәтү һәм төзекләндерү белән бәйле чыгымнарга-100 сум.

-Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлеге торак пунктларында контейнерлар сатып алу һәм каты көнкүреш калдыклары өчен контейнер мәйданчыкларын төзекләндерүгә бәйле чыгымнарга-100 сум.

4.Халык җыены нәтиҗәләрен Салман авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми http://pravo.tatarstan порталында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әлки муниципаль районы
Салман авыл җирлеге башлыгы: Л. Ф. Гайфуллина.